**Совет Большеачасырского сельского поселения Зеленодольского муниципального района Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге Советы**

РЕШЕНИЕ
19 июль 2019 ел

КАРАР
№213

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге Советының 2016 елның 27 июнендәге 65 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (2017 елның 20 декабрендәге 131 номерлы үзгәрешләр белән)

«Чит ил инвесторы төшенчәсен төгәлләштерү өлешендә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 31 маендагы 122-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Олы Ачасыр авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге Советының 2016 елның 27 июнендәге 65 номерлы Карары (2017 елның 20 декабрендәге 131 номерлы үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турындагы нигезләмәгә (алга таба - нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.8 пунктта «ачык» сүзен «халык алдында» сүзе белән алмаштырырга»;

1.2. 1.9 пунктта дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган дәүләт яисә территориядә теркәлгән юридик затлар исемлегенә кертелгән һәм (яисә) финанс операцияләре уздырганда мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмаган, һәм алар Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә үзенең файдалы кулланучылары, бенефициар хуҗалары һәм контрольлек итүче затлар турында мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмаган дәүләтләрнең һәм территорияләрнең исемлеге;»;

1.3. Нигезләмәнең 1.9 пунктның бишенче, алтынчы абзацлары үз көчен югалткан дип танырга;

1.4. 1.10 пунктының икенче абзацында «ачык» сүзен «халык алдында» сүзе белән алмаштырырга»;

1.5. 3.2 пунктта «ачык» сүзен «халык алдында» сүзе белән алмаштырырга;

1.1. 4.2 пунктта «ачык» сүзен «халык алдында» сүзе белән алмаштырырга;

1.7. 5.2 пунктта «ачык» сүзен «халык алдында» сүзе белән алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Олы Ачасыр авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында: Олы Ачасыр авылы, Үзәк урам, 46 йорт

(җирлек администрациясе бинасы), Олы Ачасыр авылы, Кооператив урамы, 26 йорт (мәдәният йорты бинасы) адреслары буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл жирлеге башлыгына йөкләргә.

**Олы Ачасыр авыл жирлеге башлыгы, Совет рәисе** **М.Г. Гатиятуллин**